**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2976**
**11.06.2019**

Муниципаль ихтыяҗлар өчен
җир участогын кире алу турында

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 63 микрорайоны территориясен планлаштыруның расланган проектында каралган җирле әһәмияткә ия объектларны төзү максатында, РФ Җир кодексының 11, 49, 56.2, 56.3, 56.6, 56.7, 56.8, 56.10 маддәләре, Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 63 микрорайонын планлаштыру проектын раслау турында» 2016 елның 13 июлендәге 3556 нчы карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Муниципаль ихтыяҗлар өчен кире алырга:

1) Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Габдрахман Әбсәләмов проспекты адресы буенча урнашкан Фәхретдинов Рөстәм Альберт улының милекчелек хокукындагы мәйданы 2443 кв.м булган җир участогын (кадастр номеры 16:52:070308:628), рөхсәт ителгән файдалану төре - «автомобиль транспорты»;

2) Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Габдрахман Әбсәләмов проспекты адресы буенча урнашкан «Эссен Продакшн АГ» ЯАҖ милекчелек хокукындагы мәйданы 1145 кв.м булган җир участогын (кадастр номеры 16:52:070308:629), рөхсәт ителгән файдалану төре - «автомобиль транспорты».

2. Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенә:

1) әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 10 көн эчендә әлеге карарны «Челнинские известия» газетасында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә;

2) әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 10 көн эчендә, закон тәртибендә билгеләнгәнчә әлеге карарның күчермәсен әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир участогына хокукы булган затка җибәрергә;

3) әлеге карар кабул ителгән көннән башлап 10 көн эчендә әлеге карарның күчермәсен Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсенең Яр Чаллы бүлегенә җибәрергә;

4) кире алу нәтиҗәсендә туктатылган хокукларны һәм китерелгән

зыянның күләмен бәяләү, шулай ук кире алынган күчемсез милеккә алмашка бирелә торган күчемсез милекне бәяләү өчен бәяләүче оешманы билгеләргә;

5) җир участокларын кире алу буенча эш йомгаклары буенча дәүләт яки муниципаль милектә булган җир участокларын, шәхси милектә булган җир участокларына алмашу килешүе әзерләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм җир мөнәсәбәтләре идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин